Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге составына керүче
Шомбыт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

30 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 30 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шомбыт авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны кышкы карап тоту һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын карап тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу);
- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (пирс төзелеше, янгын сүндерү гидрантлары, янгын җиһазләре, күрсәткечләр сатып алу);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу, территорияләрне җыештыру, коймалар төзү.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 257 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 161 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 161 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбытавыл җирлеге составына керүче Шомбыт авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шомбыт авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны кышкы карап тоту һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын карап тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу);
- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (пирс төзелеше, янгын сүндерү гидрантлары, янгын җиңсәләре, күрсәткечләр сатып алу);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу, территорияләрне җыештыру, коймалар төзү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт;Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 ж йорт;Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сергеев Н.Е.

Шомбыт авыл җирлеге башлыгы: Сергеев Н.Е.